ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

03.05.2024 ел Баулы шәһәре №71

Баулы муниципаль районы милкендә булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан мондый милекне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда сатып алына торган арендага бирелә торган күчемсез һәм күчемле милеккә түләүне бүлеп бирү срогын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы, «Дәүләт яки муниципаль милектә булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан арендага алынган күчемсез милекне читләштерү үзенчәлекләре һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы Федераль законнарына ярашлы, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы милкендә булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан мондый милекне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда сатып алынган, арендага алынган милеккә түләүне бүлеп бирү вакыты күчемсез милек өчен - биш ел һәм күчемле милек өчен - өч ел тәшкил итә.

2. Әлеге карарның 1 пункты нигезендә билгеләнгән чикләрдә арендага алынган күчемсез һәм күчемле милеккә түләү тәртибен (бер тапкыр яки рассрочкага), шулай ук бүлеп бирү срогын сайлау хокукы арендага алынган милекне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда кече яки урта эшмәкәрлек субъектына карый.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисади үсеш буенча урынбасарына йөкләтергә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын вакытлыча башкаручы И.И. Хөснуллина